**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 февраль № 111

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 11 март, 144 нче; 2016 ел, 24 март, 164 нче; 2016 ел, 15 август, 563 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымтаның 1 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле «м» пунктчасы өстәргә:

«м) акланган затлар һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затлар – прокуратура органы яки эчке эшләр органы тарафыннан бирелгән сәяси репрессияләр корбаннарын аклау турында яки затларны сәяси репрессияләргә дучар булган һәм акланырга тиеш дип яисә сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип тану хакында белешмә күчермәсе.»;

Тәртипкә 5 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\111.doc

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә 5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 21 февраль, 111 нче карары редакциясендә)

Форма

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында
акт

__________________________________________________________ яшәүче
адрес

граждан __________________________________________________________
Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)

адвокат __________________________________________________________
Ф.И. Ат.ис. (соңгысы – булганда), адвокат оешмасы исеме

__________________________________________________________ тарафыннан

түләүсез юридик ярдәм күрсәтелде:

| Т/с | Түләүсез юридик ярдәм төре | Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү көне | Адвокатларның хезмәте өчен түләү күләме, сум | Күрсәтелгән түләүсез юридик ярдәм берәмлеге саны | Адвокатларның хезмәте өчен түләүнең гомуми күләме, сум | Түләүсез юридик ярдәм алган граждан имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Телдән хокукый консультация бирү | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| 2. | Язма рәвештә хокукый консультация бирү | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Дәгъва гаризасы язу | | | | | |
| 4. | Апелляция, кассация, күзәтчелек шикаяте язу | | | | | |
| 5. | Соратулар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм башка хокукый характердагы документлар язу | | | | | |
| 6. | Граждан мәнфәгатьләрен дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда яклау * | | | | | |
| 7. | Граждан мәнфәгатьләрен судларда яклау * | | | | | |
| 8. | Граждан янына барып, түләүсез юридик ярдәм күрсәтү:**<br>I төркем инвалидның яшәү урыны буенча;<br>психиатрия дәвалау учреждениесенә;<br>өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү учреждениесенә;<br>балигъ булмаганнарның күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениесенә, шулай ук балигъ булмаганнарны иректән мәхрүм итү урыннарына | | | | | |

***** Гражданнар мәнфәгатьләрен дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда, судларда яклау адвокат көн дәвамында эшнең дәвамлылыгына бәйсез рәвештә фактта йөкләмәне башкару белән мәшгуль булган көннәрдә исәпләнә.

****** Түләүсез юридик ярдәм күрсәткәнгә адвокатның хезмәте өчен түләү күләме кимендә 50%ка арта.

Адвокат ______________________ (________________________)

Имза Имзаның аңлатмасы

20___елның _____ ______________

________________________